ГЛАВА СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старый Каразерик, ул.Советская,
д.12, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Иске Каразирек авылы, Совет урамы,
12 йорт,
423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 2** **05 ноябрь 2023 ел**

Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлегенең Иске Каразерик торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Иске Каразерик авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләренә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Иске Каразерик авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 16 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлегенең Иске Каразерик торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлегенең Иске Каразерик торак пунктында Совет урамы, 15 йорт адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасы янында 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлегенең Иске Каразерик торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Иске Каразерик авылындагы Совет, Ленин урамнарында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, ком-гравий катнашмасы салу, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Каразирек авылы юлларын грейдерлау, кышкы чорда кардан чистарту (трактор өчен ягулык, запас частьлар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Иске Каразерик авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразерик авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб - адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

«Иске Каразирек авыл җирлеге»
Муниципаль берәмлек башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Э.М.Минниярова